ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«9» июль 2019 ел. № 508

Россия Федерациясенең 2008 елның 24 апрелендә чыккан "Опека һәм попечительлек турында" гы 48 номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы "Балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында" гы 423 номерлы карары, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 елның 14 сентябрендәге "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 423 номерлы Карарын гамәлгә ашыру турында"гы 334 номерлы боерыгы, 2008 елның 20 мартында чыккан «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" гы 7 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшереп тору тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта)

2. "Опека һәм попечительлек органының балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешманы планлы тикшерү графигын расларга. (2 нче кушымта)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/ ) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И.Гарифҗановка йөкләргә.

Арча муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
башкарма комитетынын
2019 елның 9 шагыйнь чыккан
508 нче номерлы карарына
**1нче кушымта**

Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерү тәртибе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип 2008 елның 24 апрелендә чыккан «Опека һәм попечительлек турында» 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 5 пунктынтормышка ашыру максатында, медицина оешмалары, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар яки башка оешмалар, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары белән расланган, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 13.03.2015 ел, № 235 боерыгы белән расланган һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты белән гражданнар сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органы вәкаләтләрен тапшыру турында шартнамәләр төзелгән оешмалар эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели.

1.2. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 елның 14 сентябрендә чыкаан «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 18.05.2009 ел, № 423 карарын гамәлгә ашыру турында» гы 334 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә, опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешма эшчәнлеген контрольдә тоту Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген контрольдә тоту әлеге оешманың эшчәнлеген тикшерү юлы белән башкарыла.

2. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлегенә тикшерүне үткәрү регламенты

2.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерү Татарстан

Республикасының 2008 елның 20 мартында чыккан «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» гы 7-ТРЗ номерлы законы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеген тикшерү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының бер вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы ике муниципаль хезмәткәре составындагы комиссия (аларның берсе комиссия рәисе булып торган очракта) тарафыннан үткәрелә ала.

2.3. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерү планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

2.3.1. План буенча тикшерү булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган еллык тикшерүләр планына кертелгән тикшерү санала.

2.3.2. Бер оешмага карата планлы тикшерү, килешү нигезендә, балигъ булмаган гражданнарны опекуннар яки попечительләр булырга яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны әзерләү өчен юнәлеш бирелгән очракта, елга бер тапкыр гына үткәрелә.

2.3.3. Планлы тикшерү оешманың урнашу һәм эшчәнлек урыны буенча үткәрелә (күчмә тикшерү).

2.4. Тикшерү планына кертелмәгән тикшерү планнан тыш тикшерү булып тора.

2.4.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары нигезендә түбәндәге очракларда планнан тыш тикшерү үткәрә :

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда оешма тарафыннан аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга карата шикаятьләр белән гражданнарның мөрәҗәгатьләре булганда;

- дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан һәм гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда оешма эшчәнлегендә закон бозу очраклары булу турында мәгълүмат керү.

Планнан тыш тикшерү әлеге пунктта күрсәтелгән очраклар килеп чыкканда чикләнмәгән күләмдә оешмага чыгып яисә чыкмыйча үткәрелә.

2.5. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшергәндә

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары хокуклы түгел:

- әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кагылмаган закон таләпләренең үтәлешен тикшерергә;

- тикшерүгә кагылмаган документлар, мәгълүматлар бирүне таләп итәргә;

- әлеге Тәртип белән билгеләнгән тикшерү срокларын арттырырга.

2.6. Вазыйфаи зат (муниципаль хезмәткәр) опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерүне үткәрү максатларында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган тикшерү үткәрү турында мәгълүмати хат җибәрә:

- тикшерү формасы турында (урынга чыгып, урынга чыкмыйча гына);

- тикшерү рәвеше турында (планлы, планнан тыш);

- тикшерүне үткәрү вакыты турында (башлану һәм тәмамлау вакыты).

Тикшерү үткәрү турында мәгълүмати хат оешмага тикшерү башланган көнгә кадәр 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.7. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзаларының хокуклары:

- тикшерү максатларына ирешү өчен кирәкле булган барлык документларны (мәгълүматны) оешманың вазыйфаи затларыннан соратып алырга, шулай ук тикшерү барышында туган мәсьәләләр буенча язмача һәм телдән аңлатмалар таләп итәргә;

- тикшерү материалларына җәлеп итү өчен тикшерүгә кагылышлы документларның күчермәләрен алырга.

2.8. Урынга чыгып тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты (күчмә тикшерү) 2 (ике) эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.9. Күчмә тикшерү тәмамланганнан соң Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия тарафыннан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, оешманың документларын һәм вазыйфаи затларының аңлатмаларын өйрәнү нәтиҗәләреннән чыгып, тикшерү акты төзелә.

2.9.1. Тикшерү акты кәгазьдә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә.

2.9.2. Тикшерү актында түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

- тикшерү үткәрү көннәре санын күрсәтеп, тикшерү актын төзү датасы, урыны һәм вакыты;

- тикшерү рәвеше һәм формасы;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының тикшерү үткәрү турындагы карарының датасы һәм номеры;

- тикшерү үткәрелгән оешманың исеме;

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары (комиссия рәисе күрсәтмәләре белән);

- тикшерү үткәрү өчен оешма тарафыннан тәкъдим ителгән (тәкъдим ителмәгән) документлар (мәгълүмат);

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашырганда оешма эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозулар;

- тикшерү тәмамлану датасына опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан аның эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозуларны һәм кимчелекләрне төзәтү;

- тикшерү нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм нәтиҗәләр;

- оешма җитәкчесен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру яки танышудан баш тарту турында мәгълүматлар.

2.9.3. Тикшерү акты Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана. Тикшерү актында комиссиянең аерым әгъзалары имза куя алмаган очракта аның сәбәбе турында аңлатма бирелә.

2.9.4. Тикшерү актына тикшерүгә кагылышлы документлар яки аларның күчермәләре, шул исәптән оешманың вазыйфаи затларының закон бозу очракларында биргән аңлатмалары теркәлә.

2.9.5. Тикшерү актының бер нөсхәсе оешма җитәкчесенә башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан расланганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.10. Оешмага чыкмыйча тикшерүТатарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яки комиссия тарафыннан оешмадан соратып алынган документлар һәм оешманың вазыйфаи затлары язган аңлатмалар буенча үткәрелә.

2.1. Оешма җитәкчесе опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлегенә кагылышлы барлык документларны тикшерү үткәрү турындагы мәгълүмати хатта күрсәтелгән вакытка тапшырырга тиеш.

2.1.2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча башкарма комитет аның нәтиҗәләре турында белешмә әзерли. Белешмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе белән килештерелә. Белешмә оешмага Арча башкарма комитеты җитәкчесе белән Килештерүдән соң 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча заказлы хат белән җибәрелә.

Арча муниципаль районы
башкарма комитетынын
2019 елның 9 июля чыккан
508 нче номерлы карарына
**2нче кушымта**

Балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген

ТИКШЕРҮ ПЛАНЫ

| Тикшерү үткәрү ешлыгы | Тикшерү үткәрү ае | Тикшерү үткәрү вакыты | Срогы |
|---|---|---|---|
| Елга 1 тапкыр | Ноябрь | Айның 2нче атнасы | 1көн |